ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

04.12.2020 — 38

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Русское Макулово

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетыннан физик затларга сөт җитештерү һәм сату буенча шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу хокукына ия булучыларны сайлап алу буенча комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014нче елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2014нче елның 21нче февраленнән 104нче номерлы Карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетыннан физик затларга сөт җитештерү һәм сату буенча шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу хокукына ия булучыларны сайлап алу буенча комиссия төзергә.
2. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетыннан физик затларга сөт җитештерү һәм сату буенча шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу хокукына ия булучыларны сайлап алу комиссиясе составын расларга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан субсидия алу хокукына ия булган физик затларга сөт җитештерү һәм сату буенча шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы чыгымнарның бер өлешен каплауга дәгъва кылучылар сайлап алу комиссиясе турында Нигезләмәне расларга.
4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе: Л. Р. Цветкова

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Башкарма
Комитетының 2020нче елның 4нче
декабреннән 38нче номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан физик затларга сөт җитештерү һәм сату буенча шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу хокукына ия булучыларны сайлап алу буенча
КОМИССИЯ СОСТАВЫ

Комиссия рәисе:

Матвеева А. И – Макыл авыл җирлеге башлыгы

Комиссия әгъзалары:

Цветкова Л. Р. - Макыл Башкарма комитеты җитәкчесе

Тихонова Ю. А. – 1 нче номерлы Рус Макылы сайлау округы депутаты

Родионов И. В – 3 нче номерлы Рус Макылы сайлау округы депутаты

Хәкимов Р. Т – 10 нчы номерлы Клянчино сайлау округы депутаты

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2020нче елның 4нче
декабреннән 38нче номерлы карарына
2нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан физик затларга сөт җитештерү һәм сату буенча шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу хокукына ия булучыларны сайлап алу комиссиясе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан физик затларга сөт җитештерү һәм сату буенча шәхси ярдәмче хуҗалыкларның чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр алу хокукына ия булучыларны сайлап алу комиссиясе (алга таба-комиссия) Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетының консультатив органы булып тора.

1.2. Комиссия төзелә, аның составы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

1.3. Комиссия составына Макыл авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге депутатлары, Башкарма комитетның башка хезмәткәрләре, җәмәгать хезмәткәрләре керә.

1.4. Комиссия рәисе-Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башлыгы.

1.5. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләренә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, авыл җирлегенең башка норматив хокукый актларына таяна.

2. Максат һәм бурычлар

2.1. Комиссиянең төп максатлары булып тора:

- Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан субсидия алу хокукына ия булучыларны сайлап алу;

- субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен эшләү;

2.2. Комиссиягә түбәндәге бурычлар йөкләнә:

- субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тоту.

3. Комиссиянең эш регламенты

3.1. Комиссия карар кабул итә:

- сәбәпләрен күрсәтеп, субсидия бирү яки бирүдән баш тарту турында.

3.2. Комиссия карары аның Рәисе яисә комиссия әгъзалары инициативасы белән үткәрелә торган утырышларында кабул ителә һәм, кирәк булганда, беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе: Л. Р. Цветкова